ГЛАВА НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Заводская, д.5, с. Нижний Услон, 422574

Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан, 422574

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

13.11.2019 с. Нижний Услон 04

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Воробьевка авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 28 ноябренә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2020 елда Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Воробьевка авылында авыл эчендәге юлларга вак таш җәю

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Воробьевка авылы, Зеленая урамы адресы буенча урнашкан часовня янында 13.00 сәгатьтә халык җыены үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге
Башлыгы А.З.Шайдуллин